ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса, Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы, Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 17 декабря 2025 г.** **№ 41**

**Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым
акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы " Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 63 номерлы Урта Курса авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 24.11.2025 № 1, 24.11.2025 № 2, 25.11.2025 № 3, 25.11.2025 № 4, № 5, 26.11.2025 № 6 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы " Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2024 елның 11 декабрендәге 19 номерлы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: РТ, Арча районы, Урта Курса авылы, Тукай ур., 21 йорт; РТ, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп ур., 16а йорт; РТ, Арча районы, Түбән Курса авылы, Мәскәү ур., 30а йорт; РТ, Арча районы, Алан авылы, Һ. Такташ ур., 23 йорт каршында; РТ, Арча районы, Сарай-Чокырча, Б. Красная ур., 21 йорт; РТ, Арча районы, Корайван авыл, М.Гафури урамы, 9 йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

Урта Курса авыл җирлеге
башкарма комитетының
17.12.2025 ел, № 41
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2026 елның 26 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) тумыштан инвалидлар,

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Урта Курса авыл җирлеге
башкарма комитетының
17.12.2025 ел, № 41
карарына 2 нче кушымта

Урта Курса авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N _______________

Түләүченең Ф.И.А.и__________________________________________

Адресы:____________________________________________________

Нигезе______________________________________________________

Сезгә _________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү_________________суммада _______ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:_____________________________

алучының банкы БИК ____________________________

Сч. N _______________________________________

Алучы Сч. N ______________________________

ИНН ___________________________________________

КПП ___________________________________________

КБК _________________ОКАТО __________________

Түләүнең билгеләнеше _________________________________________

Җитәкче _________________ ____________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Иске Чүриле авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада ________________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ________________________________________

Адресы: _______________________________________________________

Алдым "___" _______________ 20__ ел ___________________________
(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитетында кал а